# Яңа көн

Балык бистәсе районы Олы Елга урта гомуми белем бирү мәктәбе

***ноябрь***




## Бу санда:

- *Шәфкатьлелек бизи кешене*
- *Мәрхәмәтлерәк булыйк*
- *26 ноябрь - Әниләр көне*

Актыккы сулышны алганда
Уфтанмас өчен җан ачынып-
Кулларда егәрлек булганда,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Күтәрик егылган гөлләрне,
Матурлык калмасын басылып.
Холкыбыз бик сабыр булса да.
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Ходаның һәр бирмеш көнендә
Бер матур як белән ачылыйк:
Һәркемнең гомере бер генә,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

# Шәфкатьлелек бизи кешене



Барыбыз да яхшылыкка мохтаҗ,
Бу заманда бигрәк.
Яхшылыкны эшләү җиңел түгел,
Ә эшләргә кирәк!

Шәфкатьлелек, яхшылык кебек күркәм сыйфатлар татар халкында иң югары бәяләнгән. Бу изге гамәлләр турында мәкаль һәм әйтемнәр иҗат ителеп, алар еллар дәвамында безне рухи яктан баета, әдәплелеккә өйрәтә.. 1. Яхшылык җирдә ятмый. 2. Җылы сүз - җан азыгы. 3. Олыны олы ит, кечене кече ит. 4. Ашның мае бар, сүзнең җае бар. 5. Яхшы гадәт адәм итәр, яман гадәт әрәм итәр.

Авылыбызда элек-электән ятимнәргә, гарипләргә, язмыш кимсеткән кешеләргә карата аерым бер гадәт яшәп килә. Аларны кызганганнар, хәлләренә кергәннәр, кулларыннан килгәнчә ярдәм иткәннәр.

Без 7 нчы класс укучылары кешелеклелек, шәфкатьлелек сыйфатларын узебездә тәрбиялибез. Бик теләп Фатыйма апага булышырга йөрибез. Бакчаларын казып китәбез, өй эшләрендә булышабыз

“Яхшылык кыл, яхшылыкта бар файда,
Кем яманлык кылса, ул таба җәза.

Элеге шигъри юллар без тимурчылар турында билгеле. Хәзерге заманча итеп әйткәндә без волонтёрлар булабыз. Фатыйма апа безне үзе дә көтеп ала. Без килгәч аның моңсу күзләре шатлыктан елмая башлыйлар. Безнең белән бергә елмаеп сөйләшүләр, кулешүләр аны тагын да нурландырып җибәрә. Ул гүя яшәреп китә. Яшь чакларын безгә сөйләп күрсәтә. Нинди авыр заманнарны күргән буын кешеләре бит алар!


Өлкәннәргә, үзебездән кечеләргә, көчсезләргә һәрвакыт, һәркайда игътибарлы, мәрхәмәтле булырга кирәк..Димәк, элек-электән үк игелек, шәфкатьлелек бик тирән мәгънәле сүзләр булганнар. Халыкта игелек кылу зур савап саналган, кылган игелек юкка чыкмый, кире әйләнеп кайта. Татар халкында мондый мәкаль бар: “ Җылы җил боз эретә, җылы сүз җанны эретә” Кешеләргә генә түгел, табигатькә ,үсемлекләргә һәм хайваннарга карата да игътибарлы булырга һәм яхшылык эшләргә кирәк

Р.Миңнуллинның “Яхшылык” дигән шигыреннән өзек белән тәмамлыйсым килә!

Яшәү безгә авыр булыр иде
Яхшылыктан башка.
Шуңа күрә яхшылыкны эшлик
Без үзебез башта.

7 нче сыйныф укучылары

# Мәрхәмәтлерәк булыйк



Җирдә күпме кешеләргә
Кирәк таяныч, терәк.
Мәрхәмәтебез белән без
Булыйк мәһабәтлерәк.

Ярдәм итү элек-электән татар халкына хас асыл сыйфатларның берсе булган. Без 6 нчы сыйныф укучылары башлангыч сыйныфтан бирле авылыбыздагы Бөек Ватан сугышы ветераннарына, тыл ветераннарына, ятимнәргә һәм ялгыз әби-бабайларга ярдәм итеп киләбез.Без бу уку елында тыл ветераны Фатыйма әбине һәм Бөек Ватан сугышы ветераны Мөхәммәт бабайны шефлыкка алдык. Без алар янына атнага ике тапкыр дәресләрдән соң барабыз. Кыш көне карлар көрәдек, өйләрен җыештырдык. Бәйрәмнәрдә матур итеп котлап кайтабыз, мәктәптәге класс чараларына чакырабыз. Аларны узебезнең сәнгатьле шигырьләребез, җырларыбыз белән сөендерәбез.

Өлкәннәргә игътибарлы, шәфкатле булыйк! Бу сыйфатларга безне сыйныф җитәкчебез Нәйсә Флюровна гел өйрәтеп тора.

"Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне" диган бит халык мәкалендә дә.

Өлкәннәргә булышу бик игелекле эш.. Мондый эшләр һәркемнең дә кулыннан килми. Ләкин, кайчакта безнең өлкәннәребезгә һәр кеше дә эшли ала торган гап-гади игътибар да җитеп бетми. "Тәмле сүз- җан азыгы" диләр. Җылы караш, тәмле сүзләребезне кызганмыйбыз аларга. Үзебезне дә алда картлык көткәнен онытмыйк.

Беркемне дә картлык урап узмый,
Гомерләрнең була мизгеле
Картаерга бер дә теләмәсәк тә
Яшьлек кире кайтмый билгеле

Күкләребез гел аяз, күңелләребез тыныч булсын. Изгелек җирдән китмәсен. күңелегез һәрвакыт изгелектә булсын. Чыгышымны Ф.Яруллинның тагын бер матур шигыре белән тәмамлыйм:



Ходаның һәр бирмеш көнендә
Бер матур як белән ачылыйк:
Һәркемнең гомере бер генә,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

6 сыйныф укучылары

«Менә син иртә белән йокыдан уяндың да күзләреңне ачтың. Бүлмә кояш нуры белән балкып тора. Өйдә тәмле аш исе аңкый. Синең өс-баш киемнәрең урындыкка пөхтәләп җыеп куелган. Сиңа рәхәт-рәхәт.

Син шул вакытта үзеңдә сизмәстән «әни» дип эндәшәсең. Нигә? Чөнки хәзер бу иртәнге сәгатьтә синең йөрәгеңдә шатлык тыпырчына һәм ул менә хәзер «әни» дигән сүз булып синең күкрәгеңнән очып чыкты да ананың күңеленә барып кунды. Ананың йөзе елмайды, күзләре энҗе ташлары кебек ялтырап китте. Нигә? Чөнки «әни» дигән сүз белән аңа бу иртәнге сәгать тагы да матуррак булып китте. Аның күңеле татлы хисләр белән тулды.

Әни. Нинди зур сүз бу!

Кеше үз гомерендә шул сүзне ничәмә-ничә кабат әйтә икән? Әйткән саен, ул сүз яңадан-яңа мәгънә алып килә. Ана шул бер сүздән синең шатлыгыңны да, кайгыңны да, уйларыңны да белә. Алай гына түгел, анна бу сүз аша синең йөрәгеңне күрә. Әйе, күрә. Чөнки «әни» дигән сүз ул үзе йөрәктә туа. Ә йөрәктән чыккан сүз йөрәккә барып керә. Әни дип әйттеңме, син инде көчледә, син инде бәхетледә!»

(Нәби Дәүли «Әни»)

